ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«31» март 2025 ел

**КАРАР**
№ 48

Торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен куллану турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 01.02.2025 нче елгы 40 нчы номерлы Эксперт- консультация НП советы "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" хаты нигезендә, торак күчемсез милек өлкәсендә социаль программаларны гамәлгә ашыру максатларында Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты карар бирэ:

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү өчен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясен билгеләү өчен 50 370 сумны кулланырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 27 мартындагы 33 номерлы «Торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясен куллану турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе

И.Д. Габдрахманов